# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче Лесхоз торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

21.11.2020 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 22 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2020 елның 21 нояберендә узган гражданнар җыенында «2021 нче елда Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенә керүче Лесхоз торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенең Лесхоз торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә тезелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Лесхоз бистәсендә яр буе урамнарын, ял итү мәйданчыкларын тезекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 832 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 428 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе ечен халык җыенында катнашкан 428 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе ечен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче Лесхоз торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2021нче елда Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Лесхоз торак пунктында Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге составына керүче Лесхоз торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Лесхоз бистәсендә яр буен, урамнарны, ял итү мәйданчыкларын тезекләндерү, карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/mesha адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Мишә авыл
җирлеге башлыгы

А.Х.Гатиятуллин